СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

НУРЛАТ РАЙОНЫ ИҖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА НУРЛАТСКОГО РАЙОНА.

16 сентябрь, 1998 ел.
ЧӘРШӘМБЕ

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | № 105 (8262) | Бәясе билгеләнгәнчә

## КАЗУЫН ДА ТИЗЛӘТӘСЕ, ТАШУЫН ДА

### ХАКИМИЯТТӘ КИҢӘШМӘ

13 август көнне район хакимиятендә хуҗалык җитәкчеләре катнашында узган киңәшмәне хакимият башлыгы Ф.С.Сибагатуллин алып барды. Фатих Сәүбәнович әүвәл финанс мәсьәләләрен - товар кредитын каплау, һәр тармакта төгәл исәп һәм контроль булдыру, чыгымнарга каршы технологияне районда киңрәк кертү кебек темаларны күтәрде. Киңәшмәдә төп урын җәмәгать малларын кышлатуга бирелде, аны уңышлы үткәрү өчен җитәрлек күләмдә азык туплау көнүзәк таләп итеп күтәрелде. Иптәш Сибагатуллин, быел фураж кытлыгын искә төшереп, дуңгызларны кышлату авыр булачагын белдерде, бу җәһәттән бүгеннән кайгырту алып барырга кирәклеген басым ясап әйтте, фураж кытлыгын каплау өчен катнаш силос әзерләү кирәклеген кабат ассызыклады, берочтан хуҗалыкларда азык әзерләүнең барышына анализ ясады. Киңәшмәдә шулай ук туңга сөрүнең темпын ...ләтү турында да җитди сүз булды.

**Кискен сигнал**

### ШАРТЛАР - БЕР, НӘТИҖӘ - ТӨРЛЕ

"Нурлат" агрофирмасына керүче ике хуҗалык - Синдряков исемендәге һәм "Рассвет" КХАлары турында әйтүебез. Быел бу хуҗалыкларның сөтчелек тармагында ирешкәннәре шулай уйларга нигез бирә дә. Әйтик, Синдряков исемендәге КХАда бүген көнлек савым узган елгы күрсәткеч белән чагыштырганда 5,3 килограммга артып, 13,4 килограммга җиткән бер вакытта, рассветлыларда чигенеш хөкем сөрә. Биредә көнлек савым 11,3 кг, ягъни узган елгы күрсәткечтән 1,1 кг.га кимрәк. Һәм бу тулаем нәтиҗәдә дә чагыла: ул узган елгы ...чан 1584кг.га азрак.

Продукцияне сатуга килсәк тә шундый ук хәл. Синдряковлылар 8 айда физик авырлыкта 13283 центнер сөт сатканнар, аның 95 проценты беренче сорт белән, 50 проценты беренче сорт белән суытылып озатылган. "Рассвет"та бу яктан да әлләни мактанырлык нәрсә күренми: беренче сорт белән сатылган сөт 75 процент исәпләнсә, беренче сорт белән суытылып сатылганы шулай ук 31 процент кына. Шул югалтулардан килеп чыккан түгәрәк сумнарны да атасак... Хәер, анысын хуҗалык җитәкчеләре санасын! Алар кассасын читләп үтә бит ул акчалар. Ул чакта бәлки бер үк шартларда яшәп тә җитештерүне киметүгә юл кую очраклары булмас иде.

### "Уңыш -98" матбугат үзәге хәбәр итә

*Уракның беренчесе бетәргә күп калмады инде. Әмма икенчесе - шикәр чөгендере казу бик кызу темп ала диеп булмый әле. Дөрес, кичәге көнгә бу эшкә ун хуҗалыкта керештеләр - керешүен, әмма казылган мәйданнар төрлесендә төрлечә. "Өмет" агрофирмасында татлы тамырны 200 гектар чамасы мәйданнан казып алдылар инде, "Киекле" чөгендерчеләре дә 110 гектарның уңышын чыгардылар. "Рассвет" һәм "Игенче"дә дә бу эшне ашыктыралар - беренчесендә соңгы көнне генә дә 30 гектарга якын чөгендер казылды. Уңыш әлегә "Кондырча", Синдряков исемендәге һәм шикәр заводы ярдәмче хуҗалыкларында иң югарысы. Башка хуҗалыкларда да бу эшне тизләтү зарурлыгы көн кебек, бер үк вакытта чималны заводка китерү темпын да арттыру сорала, югыйсә заводны эшләтә башлау шактый озакка сузылырга мөмкин.*

*Соңгысын әле кукуруз урагының тәмамланмавы да бераз тоткарлый, билгеле. Район буенча кукурузның 70 процентлабы урылды, 60 мең тоннадан артыграк силос салынды һәм бу төр план яртылаш диярлек үтәлде. Соңгы көннәрдә "Агрохимсервис" ярдәмче хуҗалыгында, "Кондырча"да бу эшне шактый тизләттеләр, ә менә "Татарстан", Синдряков исемендәге, Хафизов исемендәге, "Киекле" хуҗалыкларында иң ишле мәйданнарда кукуруз тамырда әле. Катнаш силос 5 мең тоннадан артыграк салынды. Соңгы вакытта бу эшкә Хафизов исемендәге, "Төрнәс", "Комбайн", "Киекле", нефтебаза ярдәмче хуҗалыкларында да тотындылар. Бер шартлы терлеккә әзерләнгән азык берәмлеге "Үрнәк", "Алга" һәм М.Җәлил исемендәге, "Төрнәс", Синдряков исемендәге хуҗалыкларда 24 - 27 центнер тирәсе.*

*Киләсе ел уңышына нигез салу җәһәтеннән бүген туңга сөрү һәм чәчүлек орлык салып куюны ашыктыру мөһим. Кичәге көнгә "Заря", "Төрнәс", "Сөлчә" һәм "Агрохимсервис" ярдәмче хуҗалыкларында беренчел планлаштырылганның 73-83 проценты туңга сөрелсә, элеккеге "Чирмешән", Кузнецов исемендәге хуҗалыкларда бу күрсәткеч 23 - 31 процент кына, "Алга", "Комбайн", РСУ һәм шикәр заводы ярдәмче хуҗалыкларында планның биштән икесе генә диярлек үтәлгән.*

### Депутатлар игътибарына!

*1998 елның 22 сентябрендә иртәнге сәгать 9да район хакимиятенең конференц - залында халык депутатларының Нурлат берләштерелгән Советының чираттагы унҗиденче сессиясе була.*

Халык депутатларының
Нурлат берләштерелгән Советы.

## АҢА ГЕЛ ЭШ ТАБЫЛА

*"Игенче" КХАсыннан Фәнис Сәлим улы Нуруллин бу. Ул - гомерлек һөнәре итеп механизаторлыкны сайлаган кеше. Җәй көннәрендә азык әзерләүдә эшләсә, көзен комбайннан кагатларга чөгендер ташып тора, ә кышын ферма малларын азык белән тәэмин итүдә эшли. Хуҗалыкта аның хезмәтеннән канәгатьләр, һәрчак мактап телгә алалар.*



*Н.АЗИЗОВ фотосы.*

## ЮБИЛЯР - ЯКТАШЛАРЫ ЯНЫНДА



***Узган җомгада районыбызга якташыбыз Тәлгат Галиуллин юбилеен билгеләп үтү өчен Казаннан бер төркем кунаклар кайтып төште. Болар - милләтебезнең тере тарихы булган аксакал әдибебез Гариф ага Ахунов, шагыйрьләр Илдар Юзиев һәм Гөлшат Зәйнашева, "халкыбызның иң зур сабые" Шәүкәт Галиев, урта буын вәкилләре Равил Фәйзуллин һәм Ринат Мөхәммәдиев, галим һәм мөгаллим, Казан радиосы дикторы буларак тавышы белән һәр татар кешесенең җанында урын алган шәхес Фоат Галимуллин, ТРның халык артисты Клара Хәйретдинова, танылган җырчы Мирсәет Сөнгатуллин, шагыйрь Әхмәт Гадел, академик якташларыбыз бертуган Галиуллиннар - Әфкать әфәнде һәм юбиляр үзе - Тәлгат ага, аларның туганнары һәм дуслары иде.***

Килүчеләрне район чигендә олылап каршы алганнан соң, кунаклар Колбай - Мораса мәктәбендә булдылар һәм Г.Кариев музеен карадылар. Ә аннан соң сәфәрчеләр Тәлгат аганың туган авылы Кычытканлыга юл тоттылар. Мәктәптә булган җылы очрашудан соң якташларының юбилярны хөрмәтләве авыл мәдәният йортында авылдашлары, туганнары даирәсендә дәвам итте. Мондагы эчкерсезлекне, күңелләрнең нинди хисләр кичерүен сүзләр белән генә аңлату мөмкин дә түгел иде. Юбилей кичәсенең үзәгендә исә 8 бала (шул исәптән ике академик) үстереп, кеше иткән һәм бүген берсенең түгәрәк юбилеен күрергә дә насыйп булган Ана утыра иде. Фоат Галимуллинның юбиляр әнкәсенә багышлап җыр башкаруы күңелләрне тагын да нечкәртеп җибәрде...

Икенче көнне Казан кунаклары районда авыл хуҗалыгын реформалаштыру барышы белән таныштылар - "Өмет" агрофирмасының ике кооперативында , "Киекле" КХАсында, Синдряков исемендәге КХАда булдылар. "Кондырча" хуҗалыгының нәселле атлар фермасындагы чабышкыларга сокландылар.

Күптән түгел генә ачылган сәнгать мәктәбебез, яңартылган аэропорт һәм Яшьләр йорты да кунаклар юлыннан читтә калмады.

Югары Нурлат һәм Кизләү мәктәпләрендә укучылар белән очрашу галимнәр һәм әдипләр өчен рухи сафлану, яңару сәгатьләре булды.

Ә кичен юбилярны хөрмәтләү өчен нурлатлылар район мәдәният йортына җыелдылар. (Бу кичә турындагы язманы газетабызның алдагы саныннан укырсыз.)

**К.ҖАМАЛЕТДИНОВА.**

## * ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕНДӘ



**** Татарстан Язучылар берлеге идарәсенең чираттагы утырышы булды. Анда Язучылар берлегенең чираттагы корылтаена әзерлекнең барышы каралды. Шул уңай белән био - библиографик белешмәләр һәм "Татарстан язучылары" дигән яңа китап чыгару кирәклеге билгеләп үтелде. Корылтай киләсе елның маенда узачак.***

*Утырышта шулай ук бу елның калган өч аенда узачак юбилей кичәләрен билгеләп үтүгә әзерлек мәсьәләләре каралды. Идарә шулай ук балалар әдәбиятын үстерүгә зур өлеш куйган шагыйрь Хәкимҗан Халиковка Абдулла Алиш исемендәге әдәби бүләк бирү турында карар кабул итте.*

*Дәүләт Советы Рәисе урынбасары шагыйрь Ренат Харис әле генә Чечен Республикасында булып кайтудан алган тәэсирләре белән уртаклашты.*

# АКЧАСЫЗ ДА КӨН КҮРЕР КӨННӘР

## ЗАМАН АГЫШЫ

Социаль тәэминат бүлегендә гаять зур җанлылык хөкем сөрә - пенсия турында белешергә яки сатып алучы карточкасы артыннан килгән пенсионерларның чуты юк. Соңгысын кулларына алып карамаганнар өчен әйтеп үтик - карт - карчыкларга пенсия исәбеннән товар бирүне тамгалап бару өчен чыгарылган кәгазь ул. Дөрес, пенсияне гел әйберләтә бирергә генә дигән сүз түгел бу, әмма акча кытлыгы заманында район җитәкчелеге пенсионерлар ничек тә очын - очка ялгап бара алсыннар өчен шул юлга барырга мәҗбүр һәм шул сәясәтне гамәлдә эшкә ашыруны дәвам итү ягында әлегә. Шул карточка буенча "Пенсионер" ("Чулпан") кибетеннән икмәк, май, сөт, эремчек, он, казылыклар һәм башка төр азык - төлек алырга мөмкин. Башта шикәр дә булып алды, әмма анысын, күрәсең, бәяләр котыруыннан курыкыптыр инде, бик тиз алып бетергәннәр, егермесеннән соң тагын кайтарырга вәгъдә итәләр. Чәй, дөге, карабодай ярмаларын, токмачны сәгате белән алып бетерәләр. Бирегә товар Пенсия фондына бурычлары булган предприятиеләрдән - райподан, азык - төлек комбинатыннан, элеватордан, сөт - май комбинатыннан, РСУдан керә. Поставщиклар исемлегенә шәхси эшмәкәрләр дә кертелгән. 3 сентябрьдән шикәрчеләр бистәсендә дә "Пенсионер" кибете ачылган.

- Сүз дә юк, пенсияне "тере" акча белән бирсәләр яхшырак анысы, - диделәр Ленин урамында торучы ике пенсионер. - Бер дә булмаганда монысы да ярый инде...

Гәрчә, "Пенсионер" кибетендә чиратлар бетмәсә дә - бирегә тимер юлчылар бистәсеннән дә киләләр бит - килгән кеше барыбер бөтенләй үк буш кул белән китми. Азык - төлекне, хуҗалык өчен башка кирәк - яракны "Нурлатнефть" НГДУсының эшчеләрне тәэмин итү бүлеге кибетләреннән дә алып була - аларда башкаларга караганда да оперативрак булдылар. Шулай ук урман хуҗалыгы ОРСы, сөт - май комбинаты, РСУ, машина төзү заводы, МСО, сәүдә базасы кибетләре дә пенсионерларга хезмәт күрсәтә. Ит комбинатының фирма кибете ит һәм ит продуктлары белән сату итә - монда барлык тиешле шартлар да булдырылган. Авыллардагы сәүдә предприятиеләре дә шушындый ысулны кулланылышка керттеләр.

- Бүгенгә шәһәрдә 3000 пенсионер шундый карточка алды һәм андыйларның саны гел арта бара,- дип сөйли халыкны социаль яклау бүлегенең баш бухгалтеры В.Н.Птичкина.

Пенсияләрне вакытында биреп барып булмаганлыктан, аларга фатир, коммуналь хезмәтләр өчен дә пенсия исәбеннән түләү мөмкинлеге бирелә. "Надежда" дәүләт предприятиесендә шул чуттан кием - салым тектерергә яки төзәттерергә мөмкин. Карл Маркс урамындагы ательеда белештек, мондый заказлар күп булмаса да, бераз бар икән. Теләге булганнар паспорт һәм пенсия кенәгәсе белән килергә тиешләр.



Н.АЗИЗОВ фотосы.

Бу мәшәкатьле чорда район элемтә бүлеге операторларына да эш артты. Пенсионерлар, телефон өчен бурычлары җыелганны көтмичә, вакытында түләп барырга күнеккән бит алар, шуңа да көн саен 30-40 кеше килә - анысын да шул карточкага язып түлиләр. Нурлат шәһәр электр челтәрендә ут өчен түләүләрне исәпләп кабул итү белән дүрт контролер шөгыльләнә. Пенсионерларга "акчасыз" хезмәт күрсәтү төрләре арта бара. Хәзер менә мунчада да "бушка" юынырга мөмкин.

"Акчасыз" түләү практикасы беренче булып Ульян өлкәсендә кулланылышка кертелгән, диләр. Татарстанда Казанның кайбер районнарында, Яр Чаллыда һәм Зәйдә шулай эшлиләр. Социаль тәэминат министрлыгында Нурлат районы тәҗрибәсенә уңай карыйлар: бу икътисад чоңгылыннан әле кайчан чыгасыбыз билгесез, ә халыкны авыр хәлдә калдырып булмый. Пенсия фондына августта районда түләүчеләрдән барлык сумманың 24 проценты гына кергән. Аның каравы, "тере" акчасыз түләүләр суммасы дистә меңнәргә җыела инде. Пенсия фондының районндагы вәкиле В.Г.Хоменко сүзләренә караганда, авылда пенсия исәбенә 96850 сумлык ашлык бирелгән, "Пенсионер" кибете аша 50 мең сумлык товар сатылган, җылылык челтәре 21 мең, электр челтәре 1,5 мең сумлык исәп - хисап ясаган, машина төзү заводы 27 мең сумлык хезмәт күрсәткән. Барлык бу эш контрольдә тотыла һәм проблемаларның зураюына юл куелмый. Барлык финанс мәгълүматлары көннеке көнгә тупланып барыла.

**Т.АЛЕКСЕЕВА.**

***СОҢГЫ СҮЗ УРЫНЫНА.*** ***Бер мичкә балны бер кашык дегет белән генә боза күрмик тагын. Пенсионерлар "үз" кибетләренә яткан товар китермәүләрен бик үтенеп сорыйлар.***

# КҮПМЕ ГОМЕРЛӘРЕ КАЛГАНДЫР...

Шәһәрдә елдан - ел күбрәк калкып килүче заманча уңайлыклы йортлар ышыгында таушалган, ишелә башлаган иске өйләр аерата фәкыйрь, мескен күренәләр, гомуми яңарып килүче шәһәр йөзен дә бизәмиләр. Бәхеткә, андый йортлар саны азая бара. Республика күләмендә гаиләләрне авария хәлендәге һәм иске йортлардан күчерү программасы кысаларында безнең районда да тузган торакны яңарту буенча программа гамәлдә. Аның нигезендә 1995 елдан 2000нче елга кадәр шәһәрдә шундый иске йортларда яшәүче 184 гаилә үз торак шартларын яхшыртырга тиеш. Бу күпме, азмы? Анысын чамалау өчен тагын бер сан гына китерү дә җитәдер: быелның 1 июленә районда 146, шәһәрдә 593 иске йорт исәпләнә. Әлбәттә, аларны бер ай, бер ел эчендә генә яңарту мөмкин түгел. Әмма бүгенге икътисадый шартларда шундый изге программа гамәлдә икән, димәк, кеше мәнфәгате турында кайгырту кимеми.

**Рәсемдә: Нурлатның бу йортлары соңгы елларын кичерәләр.**

**Н.АЗИЗОВ фотолары.**





*Туган як тарихын барлаганда*

# МУЗЕЕГЫЗ НИ ХӘЛДӘ?

Узган атнада мәгариф бүлегендә шәһәр һәм район мәктәпләренең тарих укытучылары өчен семинар үткәрелде. Семинарда агымдагы укыту - тәрбия мәсьәләләре белән беррәттән мәктәпләрдә оештырылган туган якны өйрәнү музейларының эшчәнлеге дә каралды. Узган уку елында мәктәп музейлары арасында игълан ителгән район смотрына йомгак ясар вакыт җиткәнлеге дә искәртелде. Мәгълүм булганча, Югары Нурлат, Яңа Иглай, Яңа Әмзә, Чуваш Мәнҗесе, Егоркино һ. б. кайбер мәктәпләрдә музей эшчәнлегенә зур игътибар бирелә, фәнни-иҗади юнәлештә эшлиләр. Быел, мәсәлән, Югары Нурлат урта мәктәбендә музейны яңа иркенрәк бүлмәгә күчергәннәр. Шунда ук мәгариф тарихына караган махсус бүлек оештырып киләләр. Мәктәп музеена нигез салучы, аны төзүче һәм әле бүген дә көн - төн белән исәпләшми шунда хезмәт куючы Таһир ага Гыймадиевның тәҗрибәсе, эшчәнлеге һәм киләчәккә планнары әлеге юнәлештә эшләүче һәр укытучы өчен олы мәктәп булырлык, Яңа Әмзә (җитәкчесе Ә.Г. Фәссахов), Яңа Иглай (И.Һ.Тимербулатов) музейларының эшендә дә күпләргә үрнәк булырлык яклар бар. Менә шуңа күрә дә, район смотрын йомгаклап, нәтиҗәләр ясар өчен, махсус комиссия 22 - 23 сентябрь көннәрендә барлык музейларны карап, аларның эшчәнлеге белән танышып чыгачак.

**Г.ГАФУРОВА,**
**район мәгариф бүлеге методисты.**

Сорау - җавап

# ГЕЛ ТОРАК ТУРЫНДА

***Мин әтинең сеңлесе фатирында пропискада торам. Апаның вафатыннан соң фатир миңа каламы, әллә мирас кәгазе кирәкме?***

Сораудан аңлашылмый: фатир хосусыйлаштырылганмы, әллә юкмы? Хосусыйлаштырылмаган очракта фатир дәүләткә кала. Анда яшәүчеләр дәүләт фатирында, ордер буенча урнашып, килешү шартларында яшиләр. Апагыз фатирында пропискагыз туганыгыз үлгән очракта да саклана, әмма бу яшәү барыбер дәүләт белән килешү (найм) шартларында яшәү дигән сүз.

Фатир хосусыйлаштырылган очракта апагыз фатир хуҗасы исәпләнә. Фатирны сезнең милек итү өчен,туганыгыз сезнең исемгә бүләк итү, сатып бирү яки мирас итеп калдыру турында документ (рәсми кәгазьләрне нотариуста раслап) тутырган булырга тиеш. Шулай булмаган очракта, Россия Федерациясе гражданнар кодексы нигезендә (532нче маддә)сезнең бу фатирга хакыгыз юк, чөнки сез апагыз милкенә варис була алмыйсыз.

***

***Яңа йортка күчкәндә (расселение) улыбызга ике бүлмәле, ирем белән миңа бер бүлмәле фатир бирделәр. Кызыбыз кияүгә чыкты һәм ике бүлмәле фатир сатып алды, ләкин берничә елдан иреннән аерылды.***

***Ирем үлгәч, миңа бер бүлмәле фатирымны кияүгә (кызымның ире) калдырып, кызым янына күчәргә туры килде. Хәзер без кызым белән хосусыйлаштырылган ике бүлмәле фатирда яшибез. Кызым - фатир хуҗасы. Миннән соң улымның бу фатирга хокукы бармы?***

Әгәр фатир хуҗасы кызыгыз икән, сездән соң да фатирга ул хуҗа булып кала. Башка җирдә яшәүче улыгыз кызыгыз үлгән очракта ул фатирның мирасчысы була ала. Ләкин кызыгыздан соң аның мирасына хокукы булган исән туганнарыгыз калмаган очракта гына (532нче маддә), ир һәм кыз туганнар, (әти - әни, ир балалардан кала), ир йә кыз туган, абый - апа, эне - сеңел икенче чираттагы мирасчы санала.

***

***Мин бер бүлмәле кооператив фатирда яшим. Минем янга кызым һәм оныгым теркәлгән, ләкин алар башка фатирда яшиләр. Оныгым һәм кызым өчен коммуналь хезмәтләргә акча түләргә тиешменме?***

Торак йортта яшәгән өчен түләү кертү турындагы вакытлы положениенең 3 нче пунктына нигезләнеп, даими яшәү урыныннан китү очрагында (бер айдан артык срокка) коммуналь хезмәт өчен (җылыту һәм торак йортны наемга алган өчен түләүдән кала), лифттан файдаланган, көнкүреш калдыкларын чыгарган өчен фатир хуҗасыннан гариза кергән очракта акча түләнми.

***

***Дәүләт биргән фатирдан үз фатирыңа күчеп буламы яисә хосусыйлаштырылган фатирдан хосусыйлаштырылмаганга күчәргә буламы?***

"Торак сәясәте нигезләре турында" Россия Федерациясе законының 20нче маддәсенә нигезләнеп, шуны әйтергә була: торак иясе, торак фонды иясе (ведомство яки муниципаль органнар) рөхсәте белән, хосусый милек иясе булу хокукын дәүләт фатирында торучы хокукына алмаштыра ала. Бу эш махсус килешү документы белән рәсмиләштерелә.

**("Юлдаш"тан).**

